**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ**
**2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Суык Чишмә авыл җирлегенең Чыбыклы торак пунктында**

**2025 елның 19 ноябре** **№ 1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районынын Суык Чишмә авыл җирлегенең Чыбыклы торак пунктында гражданнар җыены:

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Чыбыклы авыл җирлеге Суык Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем Инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (ремонт, юлларга вак таш җәю);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуны ремонтлау).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Суык Чишмә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Чыбыклы авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чыбыклы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Гадершин